**Образовательный минимум**

| | |
|---|---|
| **Четверть** | **2** |
| **Предмет** | **Математика** |
| **Класс** | **5** |

| | |
|---|---|
| Тигезләмә | Кыйммәтен табарга кирәк булган хәрефне эченә алган тигезлек |
| Тигезләмәнең тамыры | Тигезләмәне дөрес тигезлеккә әверелдерүче хәрефнең кыйммәте |
| Тигезләмәне чишү | Аның тамырларын табу |
| Билгесез тапкырлаучыны табу өчен | тапкырчыгышны икенче тапкырлаучыга бүләргә кирәк |
| Билгесез бүленүчене табу өчен | өлешне бүлүчегә тапкырларга кирәк |
| Билгесез бүлүчене табу өчен | бүленүчене өлешкә бүләргә кирәк |
| Тапкырлауның кушуга карата тарату үзлеге | $(a+b)\cdot c = a\cdot c + в\cdot c$ |
| Тапкырлауның алуга карата тарату үзлеге | $(a-b)\cdot c = a\cdot c - в\cdot c$ |
| 2*2*2*2*2*2= | $2^6$<br>2 саны – дәрәҗәнең нигезе, 6 саны –дәрәҗә күрсәткече |
| Юл табу формуласы | S = v · t |
| Тизлек табу формуласы | V = s : t |
| Вакыт табу формуласы | t = s : v |
| Квадрат периметры | $P = 4a$ , а – квадрат ягы |
| Турыпочмаклык периметры | Р = 2 ·(а + в), а һәм в турыпочмаклыкның яклары |
| Квадрат мәйданы | $S = a^2$ |
| Турыпочмаклык мәйданы | $S = a\cdot b$ |
| Турыпочмаклы параллелепипед күләмен табу | $V = abc$, a, b, c – иңе, буе, биеклеге |
| Куб күләмен табу | $V = a^3$, а – кубның кабыргасы |
| Мәйдан үлчәү берәмлекләре | $мм^2$, $см^2$ , $дм^2$, $м^2$, а, га, $км^2$,<br>янәшә булган зуррак үлчәү берәмлеген кечерәгенә әверелдерү өчен 100 гә тапкырлыйбыз, кечерәген зурракка әверелдерү өчен 100 гә бүләбез. |
| Күләм үлчәү берәмлекләре | $мм^3$, $см^3$ , $дм^3$, $м^3$, 1 литр = $дм^3$<br>янәшә булган зуррак үлчәү берәмлеген кечерәгенә әверелдерү өчен 1000 гә тапкырлыйбыз, кечерәген зурракка әверелдерү өчен 1000 гә бүләбез. |

**Образовательный минимум**

| | |
|---|---|
| **Четверть** | **3** |
| **Предмет** | **Математика** |
| **Класс** | **5** |

| | |
|---|---|
| Ялгыз вакланма | Санаучысы ваклаучысыннан кечерәк вакланма ялгыз вакланма дип атала, ул берәмлектән кечерәк |
| Аралаш вакланма | Санаучысы ваклаучысыннан зуррак яки аңа тигез вакланма аралаш вакланма дип атала, ул берәмлектән зуррак яки берәмлеккә тигез |
| Аралаш вакланмадан бөтен өлешен аерып алу өчен | 1) санаучыны ваклаучыга калдыклы бүләргә кирәк;<br>2) тулы булмаган өлеш бөтен өлеше була;<br>3) калдык (әгәр ул булса) – санаучы, ә бүлүче бу вакланмалы өлешнең ваклаучысы була. |
| Катнаш санны аралаш вакланма рәвешендә язу өчен: | 1) аның бөтен өлешен вакланманың ваклаучысына тапкырларга;<br>2) тапкырчыгышка вакланманың санаучысын кушарга;<br>3) табылган сумманы вакланманың санаучысына язарга, ә вакланманың ваклаучысын үзгәрешсез калдырырга кирәк |
| Ваклаучылары тигез булган вакланмаларны кушу өчен | Санаучыларын кушалар (алалар), ваклаучысын үзгәрешсез калдыралар |
| Ваклаучылары тигез булган вакланмаларны алу өчен | Кимученең санаучысыннан киметүченең санаучысын алалар, ваклаучысын үзгәрешсез калдыралар |
| Катнаш саннарны кушу (алу) өчен | Бөтен өлешләрен – аерым, вакланма өлешләрен аерым кушалар (алалар) |
| Унарлы вакланмаларны кушу (алу) өчен | 1) бу вакланмаларның өтердән соңгы тамгалары санын тигезләргә;<br>2) аларны берсе астына икенчесен өтере өтер астына туры килерлек итеп язарга;<br>3) өтергә игътибар итмичә кушарга (алырга);<br>4) җавапта өтерне әлеге вакланмалардагы өтер астына куярга кирәк |
| Санны нинди дә булса разрядка кадәр түгәрәү өчен | бу разрядтан соң килүче цифрларның барысын да нульләр белән алмаштыралар, ә әгәр алар өтердән соң торсалар, аларны төшереп калдыралар.<br>1) Беренче төшереп калдырыла яки нуль белән алмаштырыла торган цифр 5, 6, 7, 8, 9 га тигез булса, аның алдындагы цифрны 1 гә арттыралар.<br>2) Беренче төшереп калдырыла яки нуль белән алмаштырыла торган цифр 0, 1, 2, 3, 4 кә тигез булса, аның алдындагы цифрны үзгәрешсез калдыралар |
| Унарлы вакланманы 10, 100, 1000 һ.б. саннарга тапкырлау өчен | тапкырлаучыда берәмлектән соң ничә нуль булса, бу вакланмада өтерне шулкадәр цифрга уңга күчерергә кирәк |
| Унарлы вакланманы 10, 100, 1000 һ.б. бүлгәндә | бүлүчедә берәмлектән соң ничә нуль булса, бу вакланмада өтерне шулкадәр цифрга сулга күчерергә кирәк |

Әйләнә сыз, радиусын һәм диаметрын күрсәт



**Образовательный минимум**

| | |
|---|---|
| **Четверть** | **4** |
| **Предмет** | **Математика** |
| **Класс** | **5** |

| | |
|---|---|
| Унарлы вакланманы натураль санга тапкырлау өчен | 1) Өтергә игътибар итмичә тапкырларга;<br>2) Унарлы вакланмада өтердән соң ничә цифр булса, тапкырчыгышта уңнан шулкадәр цифрны өтер белән аерырга кирәк. |
| Ике унарлы вакланманы тапкырлау өчен | 1) Өтерләргә игътибар итмичә тапкырларга;<br>2) Ике тапкырлаучыда бергә өтердән соң ничә цифр булса, уңнан шулкадәр цифрны өтер белән аерырга кирәк. |
| Унарлы вакланманы натураль санга бүлү өчен | 1) Өтерләргә игътибар итмичә бүләргә<br>2) Өлештә өтерне вакланманың бөтен өлешен бүлеп бетергәч куярга кирәк. |
| Унарлы вакланманы 0,1; 0,01; 0,001 һ.б. бүлгәндә | бүлүчедә берәмлектән соң ничә цифр булса, бу вакланмада өтерне шулкадәр цифрга уңга күчерергә кирәк |
| Санны унарлы вакланмага бүлү өчен | 1) бүлүчедә өтердән соң ничә цифр булса, бүленүче белән бүлүчедә өтерне шулкадәр цифрга уңга күчерергә кирәк;<br>2) шуннан соң натураль санга бүлү гамәлен башкарырга кирәк. |
| Саннарның арифметик уртасы | берничә санның суммасын кушылучылар санына бүлүдән килеп чыккан өлеш |
| Уртача тизлекне табу өчен | Үтелгән барлык юлны хәрәкәт вакытына бүләбез |
| Процент | Йөздән бер өлешне процент дип атыйлар |
| Агым уңаена тизлек | $V_{агым\ уң.} = V_{үз\ тиз.} + V_{агым}$ |
| Агымга каршы тизлек | $V_{аг.кар.} = V_{үз\ тиз.} - V_{агым}$ |
| Почмак | Бер ноктадан чыгучы ике нур белән төзелгән фигура |
| Почмак төрләре | кысынкы - $90^o$ тан кечерәк<br>туры - $90^o$ ка тигез<br>җәенке - $90^o$ тан зур, $180^0$ тан кече<br>җәелгән - $180^0$ |